ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.04.2024 г. Заинск №264

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 226 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгы Грантлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Иң яхшы педагогларны һәм укучыларны бүләкләү, педагогик берләшмәнең инновацион активлыгын стимуллаштыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 226 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгы Грантлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 июнендәге 311 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктның 3 нче абзацын «Сәләтле укытучы – Сәләтле укучы» Зәй муниципаль районы Башлыгы Гранты турындагы нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүләр һәр җиңүче балага 10 000 (ун мең) сум һәм әлеге җиңүчене әзерләгән педагогка 20 000 (егерме мең) сум һәм һәр призер балага 5 000 (биш мең) сум һәм әлеге призерны республика һәм Бөтенроссия укучылар олимпиадасының йомгаклау этабында катнашу нәтиҗәләре буенча әзерләгән педагогка 10 000 (ун мең) сум күләмендә башкарыла.»;

1.2. 1.1 пунктның 4 нче абзацын «Сәләтле укытучы – Сәләтле укучы» Зәй муниципаль районы Башлыгы Гранты турындагы нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүләр һәр җиңүче балага 20 000 (егерме мең) сум һәм әлеге

җиңүчене әзерләгән педагогка 40 000 (кырык мең) сум һәм һәр призер балага 15 000 (унбиш мең) сум һәм әлеге призерны Бөтенроссия укучылар олимпиадасының йомгаклау этабында катнашу нәтиҗәләре буенча әзерләгән педагогка 30 000 (утыз мең) сум күләмендә башкарыла.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында да урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Сафаргалиев Э.Р.
3-27-42